Беренче октябрьдә Мордовиядә Олкәннәр айлыгына старт бирелде. Тиешле указны РМ Главасы Артём Здунов имзалады.
Олкәннәр айлыгы республикада 1 октябрьдән 31 октябрьгә кадәр узачак һәм олкән буын гражданнарына багышланачак. Бу козге коннәрдә сугыш, хезмәт ветераннарына, ялгыз пенсионерларга һәм авыр тормыш хәленә эләккән олкән яшьтәге инвалидларга аерым игътибар биреләчәк.   Республиканын барлык районнарында айлык кысаларында торле чаралар - әдәби кичәләр, ял кичәләре, озын гомерлеләрне, юбилярларны, сугыш һәм хезмәт ветераннарын хормәтләv чаралары узачак. Шулай ук әби-бабайларыбызга багышланган ижади эшләр кvргәзмәләре, конкурслар, концертлар, кино кvр-сәтvләр, спорт-массакvләм чаралар, олкәннәргә торле ярдәм кvрсәтv очен торле хәйрия акцияләре оештырылачак.

Беренче октябрьдә Халыкара олкәннәр коне билгеләп vтелә. Бу бәйрәмне олкән буын вәкилләре гадәти булмаган рәвештә билгеләп vтәргә булдылар. Саранскта Экопарк территориясендә скандинавия йореше буенча шәхси беренчелек узды. Катнашуга 55 яшьтән олкәнрәк хатын-кызлар һәм 60 яшьтән олкәнрәк ир-атлар чакырылды. Призерлар һәм жинvчеләр медальләр, грамоталар һәм кыйммәтле бvләкләр белән бvләкләнде.
Беренчеләр рәтендә олкән-нәргә хормәт кvрсәтv Темников район vзәгендә һәм авылларында башланып китте. Тархан авылы олкәннәре очен айлык кысаларында торле чаралар: очрашулар, концертлар, спорт ярышлары һәм башка активлыклар оештырыла.
Волонтерлар һәм социаль хезмәтләр олкән яшьтәге кешеләрнен ойләренә аралашу, моһим мәсьәләләр турында фикер алышу һәм аларга әхлакый, эмоциональ яктан ярдәм итv очен киләләр. Мондый очрашулар олы яшьтәге кешеләр vзләрен кирәкле, яраткан итеп хис итә торган кайгыртучанлык һәм игътибар атмосферасы тудырырга ярдәм итә.
Шулай, Тархан авылы олысын, Голсем Хоснетдин кызы Мамлееванын 90 яшьлек юбилее белән котларга Аксель авыл администрациясе (бирегә Тархан авылы керә) житәкчесе урынбасары Ильмира Шарифжан кызы Дулатова, клуб заведующие Нурия Шарифжан кызы Муратова, китапханә заведующие Зульфия Рәуф кызы Муратова килгәннәр.
Әнгәмә барышында юбиляр vз тормышы турында да сойләгән.
Голсем Хоснетдин кызы озак еллар яшәгән Кривошеееводан ире һәм ике улы белән (яшәv очен шартлар кимегәч) Тархан авылына яшәргә кvченгәннәр. Анда алар жирле авыл хужалыгы предприятиесендә эшләгәннәр. Еллар vтә, башта ире, аннары уллары бакыйлыкка кvчә.
Хәзерге вакытта ул килене Альбина Рафаэль кызы белән яши. Голсем Хоснетдин кызынын дvрт оныгы, дvрт оныкчыгы бар. Ул барлык олкән яшьтәге кешеләр очен ин моһим булган якыннарынын кайгыртуы, игътибары һәм мәхәббәте белән әйләндереп алынган.

Шул ук районнын Митрялы авылында да олыларны хөрмәтләү дәвам итә. Бүген һәрбер авыл картын күреп бүләкләр белән чәчәкләр бәйләмен Фәридә Халим кызы Ялышевага, Рәшидә Каюм кызы Утешевага, Алия Алим кызы белән Алия Хасян кызы Урусоваларга, Абидулла Зариф улы Урусовка Митрял китапханә модире Венера Рашит кызы Ялышева белән клуб модире Зәйнәб Шамиль кызы Утешева тапшырганнар.
Барлык олкәннәргә исәнлек-сау-лык, иминлек, жан тынычлыгы, озын хәерле гомерләр телибез.

Наилә НАСЫРОВА